| | |
|---|---|
| СОВЕТ ШЕЛАНГОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ШИЛАНГЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

с. Шеланга

14.03.2017 № 21-87

Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеге Советының 20.04.2013 ел, № 26-129 карары белән расланган Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлегендә Җәмәгать тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлегендә яшәүчеләрнең муниципаль хокукый актлар проектлары буенча фикер алышуда катнашу хокукын тәэмин итү максатларында "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеге Уставына таянып,

Югары Ослан муниципаль районының

Шеланга авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлегендә Җәмәгать тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1.4.пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Ачык тыңлауларга мәҗбүри рәвештә чыгарыла:

1) Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеге Уставы проекты, шулай ук гамәлдәге уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр

кертү турында муниципаль хокукый акт проекты, уставка үзгәрешләр бары тик уставта беркетелгән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне һәм аларны хәл итү буенча вәкаләтләрне Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар нигезендә китерү максатында гына кертелә торган очраклардан тыш;

2) Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеге бюджеты һәм аның үтәлеше турында хисап проекты;

3) Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеген үстерү планнары һәм программалары проектлары;

4) Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлегенең генераль планы проекты, генераль планга үзгәрешләр кертү турында муниципаль хокукый актлар проектлары;

5) Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлегенең генераль планы проекты, генераль планга үзгәрешләр кертү турында муниципаль хокукый актлар проектлары;

6) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очраклардан тыш, территорияләрне планлаштыру проектлары һәм территорияләрне чикләү проектлары;

7) җир кишәрлекләрен һәм капиталь төзелеш объектларын шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү мәсьәләләре;

8) рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларыннан тайпылу, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү мәсьәләләре;

9) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында билгеләнгән тәртиптә расланган җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре булмаганда, җир участокларыннан һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалануның бер төрен башка төр файдалануга үзгәртү мәсьәләләре;

10) муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору мәсьәләләре, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясына ярашлы рәвештә, муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору өчен муниципаль берәмлек халкының тавыш бирү юлы белән яки гражданнар җыеннарында белдерелгән ризалыгын алу таләп ителгән очраклардан тыш;

11) территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары.»;

1.2. Нигезләмәнең 4.3.пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3. Җәмәгать тыңлауларын билгеләү турында карар, җәмәгать тыңлауларына чыгарыла торган муниципаль хокукый акт проекты, әгәр законнар һәм әлеге Нигезләмә белән башка срок билгеләнмәгән булса, авыл җирлегенең мәгълүмати

стендларында һәм Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында җәмәгать тыңлаулары уздырылачак көннән 10 көннән дә соңга калмыйча, мәҗбүри рәвештә игълан ителергә тиеш»;

1.3. Нигезләмәнең 7.4.пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.4. Мәҗбүри йомгаклау документы булып авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында игълан ителергә һәм халык тыңлаулары тәмамланганнан соң 5 көннән дә соңга калмыйча Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылырга тиешле ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча нәтиҗә тора »;

1.4. Нигезләмәнең 10.4.пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

10.4. Җирдән файдалану һәм торак пункт территориясенең бер өлешенә карата төзелеш кагыйдәләре әзерләнгән очракта, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар җир участокларының һәм (яки) җирлек территориясенең күрсәтелгән өлеше чикләрендә урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре катнашында үткәрелә.

- Конкрет территориаль зона өчен билгеләнгән шәһәр төзелеше регламентына үзгәрешләр кертү өлешендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр әзерләнгән очракта, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча ачык тыңлаулар шундый шәһәр төзелеше регламенты билгеләнгән территориаль зона чикләрендә үткәрелә. Бу очракларда Җәмәгать тыңлауларын үткәрү вакыты бер айдан артмый.

1.5 Нигезләмәнең 10.5.пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

10.5. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар тәмамланганнан соң, комиссия ачык тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектына үзгәрешләр кертүне тәэмин итә (шундый ихтыяҗ ачыкланганда) һәм әлеге проектны авыл җирлеге башлыгына тәкъдим итә.

- Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектына мәҗбүри кушымталар булып җәмәгать тыңлаулары протоколлары һәм җәмәгать тыңлаулары нәтиҗәләре буенча нәтиҗә тора.

10.6 Авыл җирлеге башлыгы аңа җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын, җәмәгать тыңлаулары протоколын, җәмәгать тыңлаулары нәтиҗәләре турындагы нәтиҗәне тәкъдим иткәннән соң ун көн эчендә әлеге проектны авыл җирлеге советына җибәрү яки җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын кире кагу турында Карар кабул итәргә тиеш.

2.Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Шеланга авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәнең текстын яңа редакциядә расларга.

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Шеланга авыл җирлеге башлыгы В.В.Майоров